**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СЕЛЕНГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“07” ноябрь 2023 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2023 елның 18 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Сәләнгеш авылы, Гагарин урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан Сәләнгеш авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында Колхоз урамы буенча 1-37 нче йорттан, Полевая урамы буенча 1-17 нче йорттан, Горький урамы буенча 1-25 нче йорттан, Гагарин урамы буенча 1-47нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2023 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 30 минутка Сәләнгеш авылы, Гагарин урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан Сәләнгеш авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында Калинин урамы буенча 4-43нче йорттан, Овражная урамы буенча 1-72нче йорттан, Яшьләр урамы буенча 1-9нчы йорттан, Гагарин тыкрыгы урамы буенча 1-12нче йортларында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Сәләнгеш авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.
4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2024 елда 1200 (бер мең ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин